**«Татарстан Республикасы Нурлат шәһәре 2нче номерлы «Тиенкәй» балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем муниципаль бюджет учреждениесе**

КАРАЛДЫ:

педагогик советтта
31.08.2021 ел, №1 беркетмә

РАСЛЫЙМ

Нурлат шәһәренең «Тиенкәй»
2 нче балалар бакчасы
МБМББУ мөдире _________Сагирова В.Х.
Приказ №145 31.08.2021 ел.

# Мәктәпкә әзерлек төркеменең (6-7 яшь)

# 2021-2022 нчы уку елына “Нәни артистлар” өстәмә эшенең

# эш программасы

**Программаның юнәлеше:** социаль-гуманитар
**Адрес**: программа 6-7 яшьлекләр өчен
**Үзләштерү вакыты:** 1 елда, 31 сәгать

**Өстәмә эш программасын эшләде:**

тәрбияче Салимова Лилия Рамиль кызы

**2021-2022 нчы уку елы**

**Эчтәлек**

**Бүлек № 1. Программаның төп характеристикалары комплексы** 3

1.1.Аңлатма язуы 3

1.2. Программаның максаты һәм бурычлары 4

1.3. Программаның эчтәлеге 5

1.4.Көтелгән нәтиҗәләр 9

**Бүлек № 2. Программаны тормышка ашыруның оештыру-педагогик шартлары комплексы** 10

2.1. Календарь уку графигы 10

2.2. Программаны тормышка ашыру шартлары 11

2.3. Аттестация формалары 11

2.4. Бәяләү материаллары 12

2.5. Методик материаллар 12

2.6. Тәрбиянең эш программасы 14

**Педагог өчен әдәбият исемлеге** 17

**Балалар өчен әдәбият исемлеге** 17

**Приложение 1** 18

## Бүлек № 1. Программаның төп характеристикалары комплексы

### 1.1 Аңлатма язуы

Халкыбызның “Гыйлем –кош, акыл –канат” дигән мәкале бар. Шуны истә тотып, без балаларны белемле, акыллы, сәләтле итеп тәрбияләү, аларның тормышта үз урыннарын табулары, тиешле биеклектә иркен итеп “очулары” өчен тырышабыз. Сабыйларның сәламәтлеген ныгыту, интеллектуаль, физик һәм шәхси үсешен тәэмин итү, тәрбия эшендә милли-гореф гадәтләрне куллану-балалар бакчалары эшчәнлегенең төп бурычы.Бакчадагы гомуми дәресләрдә бала яшьтәшләре һәм өлкәннәр белән аралашырга, әйберләрне танып белергә өйрәнә. Балаларны берләштерүдә, зурлар белән аралашуга өйрәтүдә, сөйләм телен үстерүдә, җәмгыятьтә үзен- үзе тота белеп, актив һәм сәләтле кеше булып үсүендә сәхнәләштерү эшчәнлегенең әһәмияте бик зур. Баланың бөтен тормышы уен. Уенда бала тирә - юнь турында, җәмгыятьнең законнары, кешеләрнең үзара аралашу матурлыгы турында мәгълүмат алып кына калмый, бу дөньяда яшәргә, үзенең мөгамәләләрен төзергә өйрәнә. Ә бу баланың игътибарлы, яхшы хәтерле, дөрес, матур, әйбәт сөйләшә белүен таләп итә. Сәхнәләштерү уеннарында катнашып, балалар образлар, төсләр, авазлар аша тирә - юнь белән танышалар, ә сораулар балаларны уйларга, анализларга, йомгаклау ясарга мәҗбүр итә. Һәр бала үзенең кичерешләрен, тойгыларын, теләкләрен, карашларын гадәти сөйләшкәндә генә түгел, ә чит тыңлаучылар алдында күрсәтә алырлык булып үсәргә тиеш. Еш кына без киң белемле, сәнгатьле сөйләшә белүчеләрне оялчан икәнен, чит кешеләр алдында югалып калуларын күзәтәбез. Бу проблемалар булмасын өчен, балалар бакчасында театр кую бик зур булышлык күрсәтә, уңай шартлар тудыра. Сәхнәләштерелгән уеннар балаларны шатландыралар. Спектакльләрдә катнашып, балалар тирә-юнь белән, төсләр, авазлар белән танышалар, ә уйланылып куелган сораулар балаларны анализларга, уйланырга, нәтиҗәләр ясарга өйрәтә. Сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәнү барышында, баланың сүз байлыгы арта, бала чиста, дөрес, аңлаешлы итеп сөйләргә өйрәнә. Сүзлек формалаша- яңа сүзләр белән баетыла.Бүген без балаларны мәктәпкә әзерләү, ике телдә сөйләшергә һәм язарга өйрәтү белән генә чикләнмичә, һәр яктан камил шәхес тәрбияләүнең бер юнәлеше булган милли культура формалаштырырга, халкыбызның милли-мәдәни рухын сеңдерергә тиешбез. Милли мәдәният дигәндә, без, халыкның мәдәни хәзинәсенең билгеле бер үсеш дәрәҗәсен һәм заман таләпләренә туры килерлек технологиясен булдыруны күзаллыйбыз.Балаларда эмоциональ-кыйммәтле мөнәсәбәтләр формалаштыруга уен, музыка, җыр, әкиятләр, театр кебек мәдәният элементлары куллану юлы белән ирешергә мөмкин. Шуны исәпкә алып,бу программа балалар бакчасында халык җырларын, биюләрен, музыка әсәрләрен башкаруны; сәнгать осталыкларын формалаштыруны, театр куюга теләк булдыруны, балаларның иҗади сәләтен үстерүгә зур игътибар бирүне максат итеп куя һәм тормышка ашыруга булышлык итә.

**Программаның юнәлеше:** социаль-гуманитар.

“Нәни артистлар” түгәрәге программасының **актуальлеге:** ФДББС яңалыгы - белем һәм тәрбия алуда универсаль гамәлләрнең берсе коммуникатив гамәлләрнең камил формалашуы. Ягъни, баланың үз фикерен диалогта һәм монолог рәвешендә башкаларга дәлилле итеп, әңгәмәдәшен кимсетмәслек итеп җиткерә белүгә әзерләү. Бу таләп – түгәрәкнең актуальлеген раслаучы мөһим дәлил дә. Балаларны

берләштерүдә, зурлар белән аралашуга өйрәтүдә, сөйләм телен үстерүдә, җәмгыятьтә үзен-үзе тота белеп, актив һәм сәләтле кеше булып үсүендә сәхнәләштерү эшчәнлегенең әһәмияте бик зур.

**Программаның яңалыгы** белем һәм тәрбия алуда универсаль гамәлләрнең берсе коммуникатив гамәлләрнең камил формалашуы. Ягъни, баланың үз фикерен диалогта һәм монолог рәвешендә башкаларга дәлилле итеп, әңгәмәдәшен кимсетмәслек итеп җиткерә белүгә әзерләү. Бу таләп – түгәрәкнең актуальлеген раслаучы мөһим дәлил дә. Балаларны берләштерүдә, зурлар белән аралашуга өйрәтүдә, сөйләм телен үстерүдә, җәмгыятьтә үзен-үзе тота белеп, актив һәм сәләтле кеше булып үсүендә сәхнәләштерү эшчәнлегенең әһәмияте бик зур.

## 1.2. Программаның максаты һәм бурычлары

**Түгәрәкнең максаты:** :

информация киңлегендә ориентлаша, мөстәкыйль рәвештә яхшы юнәлешне сайлый, чишелеш кабул итә белә торган бала тәрбияләү.

**Түгәрәкнең бурычлары :**

**Укыту( обущающие):**

- балаларда акыл һәм сөйләм телен үстерү, сәнгатьле итеп сөйләү өстендә эшләү, сүз байлыгы арттыру, аваз культурасы тәрбияләү;
- хәрәкәт күнекмәләрен формалаштыру;
- сәхнәләштерү эшчәнле генә тотрыклы кызыксынуны үстерү ;
- мимика, ишарәләр, хәрәкәтләр, интонация тәэсирле чараларын кабатлау теләге тудыру.

**Үстереш (развивающие):**

- музыка һәм хореография сәнгате нигезләре белән танышу;
- балаларда эстетик, әхлак һәм хезмәт тәрбиясен тормышка ашыру;
- балаларның сәламәтлеген яхшырту;

**Тәрбия (воспитательные):**

- сәнгатькә кызыксыну һәм мәхәббәт тәрбияләү.

**Аермалы үзәнчелек программасы -** театр сэнгатенен башка сэнгать торлэреннэн аермалы топ узенчэлеклэрен анлату; татар театр сэнгатен бала кунеленэ якынайту, анарда милли хислэр тэрбиялэу; театарнын бай хэм катлаулы тарихы белэн кызыксындыру, бигрэк тэ театрнын башлангыч этабы белэн таныштыру, анын беренче адымнары турында мэгълумат бируне куздэ тота.

**Адрес**: программа 6-7 яшьлекләр өчен, аларның нинди гендер булуына карамастан, сәламәтлекләренә каршы күрсәткечләре булмаган балаларга белем бирүгә юнәлдерелгән. Балаларны җыю шартлары: өстәмә сайлап алу үткәрмичә генә барлык теләүчеләр кабул ителә.

**Үзләштерү вакыты:** 1 елда, 31 сәгать

**Укыту формасы:** көндезге.

**Дәресләрне оештыру формасы:** төркемчә.

**Дәресләр режимы:** 1 дәрес / атнага 1 сәгать, көннең беренче яртысында.

**Дәреснең озынлыгы:** 20-25 минут.

**1.3. Программаның эчтәлеге**

**Укыту планы**

| Үткәрү вакыты | Бүлек | Тема | Атна | Сәгать саны | Сәгать саны | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | теория | практика |
| Октябрь | Өстәл театры | 1.Танышу: “Курчаклар дөньясы” | 1 | 1 | 0,3 | 0,7 |
| | | 2. “Өстәлдәге әкиятләр” | 2 | 1 | 0,3 | 0,7 |
| | | 3. “Өстәлдәге әкиятләр” | 3 | 1 | 0,3 | 0,7 |
| | | 4. Өстәл театры уйныйбыз | 4 | 1 | 0,3 | 0,7 |
| Ноябрь | Сәхнә | 1. Әкиятләргә сәяхәт | 2 | 1 | 0,3 | 0,7 |
| | | 2.”Теремкәй әкияте белән танышу” | 3 | 1 | 0,3 | 0,7 |
| | | 3. “Теремкәй” әкияте | 4 | 1 | 0,3 | 0,7 |
| Декабрь | Курчаклар | 1. “Курчаклар да сөйләшә белә” | 1 | 1 | 0,3 | 0,7 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2. “Курчаклар да сөйләшә белә” | 2 | 1 | 0,3 | 0,7 |
| | | 3. Әкият персонажлары | 3 | 1 | 0,3 | 0,7 |
| | | 4. Әкият персонажлары | 4 | 1 | 0,3 | 0,7 |
| Январь | Уеннар | 1.Җырлы-биюле, такмаклы уеннар өйрәнү. | 2 | 1 | 0,3 | 0,7 |
| | | 2.Татар халык биюе (кызлар) | 3 | 1 | 0,3 | 0,7 |
| | | 3.Татар халык биюе (малайлар) | 4 | 1 | 0,3 | 0,7 |
| Февраль | Рәсем | 1. М.Җәлилнең шигырьләренә иллюстрация | 1 | 1 | 0,3 | 0,7 |
| | | 2. М.Җәлилнең шигырь кичәсе | 2 | 1 | 0,3 | 0,7 |
| | | 3.Театр өчен атрибутлар әзерләү | 3 | 1 | 0,3 | 0,7 |
| | | 4.”Әбиемнең бишек җыры” исемле театрын сәхнәләштерү | 4 | 1 | 0,3 | 0,7 |
| Март | Эмоция һәм мимика | 1.Без әкият язабыз | 1 | 1 | 0,3 | 0,7 |
| | | 2.Төрле эмоцияләрне тасвирлау. | 2 | 1 | 0,3 | 0,7 |
| | | 3.Эмоцияне тавыш һәм мимика буенча таны! | 3 | 1 | 0,3 | 0,7 |
| | | 4.Спектакаль “Беренче театр” | 4 | 1 | 0,3 | 0,7 |
| Апрель | Тукай | 1. Балаларның рәсемнәр күргәзмәсе “Тукай әкиятләре” | 1 | 1 | 0,3 | 0,7 |
| | | 2. Г.Тукай “Кәҗә белән сарык” | 2 | 1 | 0,3 | 0,7 |
| | | 3. Әкият геройлары белән танышу. | 3 | 1 | 0,3 | 0,7 |
| | | 4. “Без-артистлар” | 4 | 1 | 0,3 | 0,7 |
| | | 5. Әкиятне сәхнәләштерү. | 5 | 1 | 0,3 | 0,7 |
| Май | Театр | 1.“ Без театр уйныйбыз! “ | 1 | 1 | 0,3 | 0,7 |
| | | 2.“ Без театр уйныйбыз! “ | 2 | 1 | 0,3 | 0,7 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 3.“ Без театр уйныйбыз! “ | 3 | 1 | 0,3 | 0,7 |
| | | 4.Соңгы дәрес | 4 | 1 | - | 1 |
| | **Нәтиҗә** | | | **31** | **9** | **22** |

*Бүлек Өстәл театры (4 сәгать)*

*Теория:* Төрле төр курчак театрлары (бармак, өстәл,бибабо ) белән таныштыру, алар белән эшләү үзенчәлекәрен карап китү.

*Практика:* Курчаклар белән эшләүне ныгыту;ширма белән эшләүнең бернчә ысулы белән таныштыру.

*Темалар: Танышу: “Курчаклар дөньясы”.“Өстәлдәге әкиятләр”.” Өстәл театры уйныйбыз”*

*Бүлек Сәхнә (3 сәгать)*

*Теория:* Балалар белән белгән әкиятләрне искә төшерү; геройларына характеристика бирү.

*Практика:* Төрле герой булып сөйләшергә өйрәнү; театр куярга теләк уяту.

*Темалар: “ Әкиятләргә сәяхәт”.”Теремкәй әкияте белән танышу”. “Теремкәй” әкияте*

*Бүлек Курчаклар (4 сәгать)*

*Теория:* Сәнгатьле сөйләм күнекмәләре үстерү.

*Практика:* Уен образлар тудыру өчен күнегүләр.

*Темалар: “Курчаклар да сөйләшә белә”. “Курчаклар да сөйләшә белә”.Әкият персонажлары*

*Бүлек Уеннар (3 сәгать)*

*Теория:* Сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү.

*Практика:* Бию хәрәкәтләрен өйрәнү.

*Темалар: Җырлы-биюле, такмаклы уеннар өйрәнү. Татар халык биюе (кызлар). Татар халык биюе (малайлар)*

*<u>Бүлек Рәсем (4 сәгать)</u>*

*Теория:* Геройлары турында сөйләшү.

*Практика: Әкиятне сәхнәләштергәндә индивидуальлек тәрбияләү.*

*Темалар: М.Җәлилнең шигырьләренә иллюстрация. М.Җәлилнең шигырь кичәсе. Театр өчен атрибутлар әзерләү.”Әбиемнең бишек җыры” исемле театрын сәхнәләштерү*

*<u>Бүлек Эмоция һәм мимика (4 сәгать)</u>*

*Теория:* Балаларны төле төр эмоцияәр беләң таныштыру (шатлык,курку,гаҗәпләнү).

*Практика:* Тавыш, жест, хәрәкәтләр ярдәмендә шул эмоцияләрне булдыру

*Темалар: Без әкият язабыз .Төрле эмоцияләрне тасвирлау..Эмоцияне тавыш һәм мимика буенча таны! Спектакаль “Беренче театр”*

*<u>Бүлек Тукай (5 сәгать)</u>*

*Теория:* Геройларга характеристика бирү .

*Практика:* Хәрәкәтләр өстендә эш.

*Темалар: Балаларның рәсемнәр күргәзмәсе “Тукай әкиятләре”. Г.Тукай “Кәҗә белән сарык”. Әкият геройлары белән танышу. “Без-артистлар. Әкиятне сәхнәләштерү.*

*<u>Бүлек Театр (4 сәгать)</u>*

*Теория:* юк

*Практика:Нәтиҗәләр*

*Темалар:”Без театр уйныйбыз!*

**1.4.Көтелгән нәтиҗәләр:**

**Укыту (обучающие):**

1.Балаларның театр турында, театр эшчәнлеге белән шөгыльләнүче профессия хезмәткәрләре турында белемнәре арта.

2.Балаларның милли культура, театр, артистлар дөньясы турында күп мәгълүмат белүе.

3.Балаларның сүз байлыгы, акыл эшчәнлеге арта, сәнгатьле сөйләү күнекмәләре формалаша.

**Үстереш (развивающие):**

1.Балаларда сәхнә сәнгатенә тотрыклы кызыксыну барлыкка килә.

2.Балаларның бәйләнешле сөйләм телләре үсү.

3.Сәхнәләштерү уеннарын үзләштерү ярдәмендә балаларның интонацияләре яхшыру, башка катнашучылар белән аралашу осталыклары арту, килешү, конфликтлы ситуацияләрне чишә белү мөмкинлекләре туу. Сәхнә тормышында үзеңне иркен тоту күнекмәләренә төшенү.

4.Үз туган ягыңның сәнгать кешеләре турында мәгълүмат алу.

**Тәрбия (воспитательные):**

1.Балаларның социаль характердагы беренчел кузаллаулары формалаша, социаль мөнәсәбәтләр системасына яраклаша белү күнекмәләре барлыкка килә.

2.Гаилә белән балалар бакчасы арасында җылы мөнәсәббәт урнашу.

## Бүлек № 2. Программаны тормышка ашыруның оештыру-педагогик шартлары комплексы

**2.1. Календарь уку графигы:**

Уку елының дәвамлылыгы: уку елы башы – 11 октябрь.

Уку елы тәмамлану: - 27 май. Атналары саны: 32.

Каникуллар дәвамлылыгы: кышкы каникуллар: 2 атна.

Җәйге каникуллар: 1 июньнән 31 августка кадәр.

**Уку чорында бәйрәм көннәре**:

- 4 ноябрь - Халыклар бердәмлеге көне;
- 6 ноябрь -Татарстан Республикасы Конституциясе көне;
- 1, 2, 3, 4, 5, 6, 8 гыйнвар - Яңа ел каникуллары;
- 7 гыйнвар - Раштуа;
- 23 февраль - Ватанны саклаучылар көне;
- 8 Март - Халыкара хатын-кызлар көне;
- 1 Май-Яз һәм Хезмәт бәйрәме;
- 2 май -Ураза бәйрәме;
- 9 Май - Җиңү көне**.**

**2.2. Программаны тормышка ашыру шартлары:**

Матди-техник тәэмин ителеш. Дәресләрне үткәрү өчен җиһазлы иркен якты бина кирәк: балалар өчен өстәлләр, урындыклар; кирәкле дидактик материал, костюмнар, аудио-видео дискалар

**Җиһазлар:**

1. Балалар өчен өстәлләр - 4 шт

2.Урындыклар- 16шт

3.Ноутбук- 1шт

4.Экран- 1шт

5. Колонкалар-1шт

6.Проектор-1 шт

7. Коробкалар, папкалр төрле материаллар

8. Костюмнар

9.Уеннар, уенчыклар

**Мәгълүмати тәэмин итү** белем бирү эшчәнлеге тематикасы буенча аудио һәм видеоязмалар (мультфильмнар).

**Кадрлар белән тәэмин итү** программаны тормышка ашыруга кирәкле компетенцияләргә ия мәктәпкәчә белем бирү педагоглары җәлеп ителергә мөмкин.

**2.3. Аттестация формалары** өлкән яшьтәге мәктәпкәчә яшьтәге балаларның белем бирү нәтиҗәләрен бәяләү 29.12.2012 ел, №273 «Россия Федерациясендә мәгариф турында» гы Федераль закон нигезендә каралмаган. Балаларның казанышларын бәяләү инструментлары аларның үз-үзләрен бәяләү һәм танып-белү мәнфәгатьләрен үстерүгә ярдәм итәргә тиеш, Программаны тормышка ашыруны контрольдә тотуның йомгаклау формалары булып Балалар эшчәнлеге продуктлары тора, алар алга таба эштә кулланылырга мөмкин. Аларның эшчәнлеге нәтиҗәләре буенча балаларга уңыш ситуациясен булдыру һәм Саклап калу өчен призлар бирелә ала. Белем бирү нәтиҗәләрен күрсәтү һәм күрсәтү рәвешләре булып йомгаклау дәресләре, конкурсларда һәм фестивальләрдә катнашу тора.

**2.4. Бәяләү материаллары** "Нәни артистлар" өстәмә белем бирү программасын үзләштерүнең старт мөмкинлекләрен билгеләү максатыннан, октябрь аенда, уен проблемалы ситуацияләре булдыру формасында старт диагностикасы үткәрелә. Бәяләү материаллары мәктәпкәчә яшьтәге балаларның үсеш дәрәҗәсен түгел, ә Педагогик процессның нәтиҗәлелеген (диагностикасын) бәяләү максатларында кулланыла. Билгеләмә түбәндәге диагностика инструментларын кулланып башкарыла:

-Сәнгатьле сөйләм

-Авазлар әйтелеше

-Дикция

-Темп

-Тавыш көче

-Хикәяләү

1 балл- “Түбән”

2 балл-“Уртача”

3 балл- “Югары”

**2.5. Методик материаллар**

Белем бирү процессын оештыру үзенчәлекләре: көндезге

Укыту һәм тәрбия ысуллары:

-сүзле, күрсәтмә, проблемалы, уен;

- бүләкләү, күнегүләр, кызыксындыру, мотивация.

Белем бирү процессын оештыру формалары:

-төркемчә.

Дәресне оештыру формалары:

- дәрес,

- уен,

- презентация,

- ачык дәрес,

- бәйрәм.

*Педагогик технологияләр:*

*Уен эшчәнлеге технологиясе*-билгеле бер сюжетны (уен, әкият) тормышка ашыру аша педагог һәм балаларның уен рәвешләрен куллануга, иҗади фикерләүне үстерүгә, хыял һәм хыялны үстерүгә, балалар коллективында аралашуны яхшырта.

*Сәламәтлек саклау технологиясе*-укыту процессында балаларның сәламәтлеген саклауга һәм ныгытуга юнәлтелгән (күзләр өчен гимнастика, бармак гимнастикасы, физкультминуткалар). Сәламәтлек саклау технологиясе төрле яклап үсеш алган, үз сәламәтлегеңә сакчыл карашлы һәм сәламәт яшәү рәвеше принципларын саклаган шәхес тәрбияләргә ярдәм итә.

*Мәгълүмати-коммуникацион технология*-укучыларга яңа мәгълүмат һәм белем алырга мөмкинлек бирә.

*Үсеп килүче белем бирү технологиясе*-якын арада үсеш зонасын булдыра, этәрә, психик яңарышларның эчке процессларын хәрәкәткә китерә.

*Хезмәттәшлектә укыту технологиясе*-эшнең төп формасы булып шәхси һәм коллектив иҗат формалары кулланыла торган дәресләр тора. Дәресләрнең характерлы үзенчәлеге: комплектлылык, уен формасы, дустанә иҗади атмосфера. Яшь үзенчәлекләренә туры китереп, дәресләрне оештыру формалары төрле: проблемалы ситуацияләрне кую һәм хәл итү, әкияти хикәя, театральләштерелгән эшчәнлек элементлары белән уен ситуацияләре.

*Уку дәресенең алгоритмы:*

Бер дәрескә якынча эш планы:

1 өлеш-кереш темасына дәресләр, максатларны билгеләү, аңлату моннан тыш, балалар ясарга тиеш.

2 өлеш-педагог биремен яки баланың үз ниятен үтәү буенча балаларның мөстәкыйльлеге.

3 өлеш-биремнең үтәлешен анализлау һәм аны бәяләү.

Дәрес уртасында физминутка үткәрелә. Балаларның игътибарын активлаштыру өчен дәрестә ИКТ чаралары кулланыла.

*Дидактик материаллар* **:**

Дидактик уеннар

Кулланма

Рәсемнәр

Китаплар (балалар һәм педагог өчен)

**2.6. Тәрбиянең эш программасы**

**Тәрбия эшенең максаты һәм бурычлары**

**Максат**: эстетик тәрбия бирү, хис-тойгыларны баету һәм шәхеснең эмоциональ өлкәсен үстерү.

**Бурыч:**

1. Балаларда эстетик зәвык формалаштыру, үз-үзеңне матур итеп тоту, аны булдыру омтылышы.

2. Дөньяга, табигатькә, көнкүрешенә һәм әйләнә-тирә мохиткә иҗади мөнәсәбәтне үстерергә.

3. Гүзәллеккә мәхәббәт, туган илебезнең һәм башка халыкларның традицияләренә һәм мәдәниятенә хөрмәт тәрбияләү.

**Эшчәнлек формалары һәм эчтәлеге**

**Уртак уеннар:** Бу традицион чаралар үткәрү барышында тәрбияви йогынты ясауның төп формаларының берсе.

Уеннарның төрле төрләре кулланыла: иҗади, хәрәкәтчән һәм аз хәрәкәтчән, халык уеннары, драматизация, квест-уеннар.

**Акцияләр**: Акцияләрдә мәктәпкәчә учреждение хезмәткәрләре, ата-аналар һәм тәрбияләнүчеләре катнаша. Акция барышында мәктәпкәчә яшьтәге балалар белем, Социаль-мәдәни күнекмәләр, актив тормыш позициясе алалар.

**Конкурслар:** Бу чаралар танып-белү эчтәлегенә ия һәм күңел ачу формасында уза. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны үстерүнең барлык юнәлешләре буенча да үткәрелә.

**Музыкаль-театральләштерелгән тамашалар**: Әлеге тамашалар театр спектакльләре, күңел ачулар рәвешендә үткәрелә.

**Коммуникатив уеннар**: Өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән аралашу күнекмәләрен формалаштыруга юнәлдерелгән. Һәр баланың күңеллелек, иркен хәл һәм эмоциональ җәлеп итү атмосферасында үткәрелә.

**Уеннар-драматизация:** Әлеге уеннар үз эченә  инсценировка, җыр, әкиятләр, зур булмаган әдәби текстлар ярдәмендә алына.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

1. Сәнгать-эстетик зәвыкка ия.

2. Көнкүрештә, табигатьтә, сәнгатьтә матурлыкны кабул итәләр һәм тоеп яшиләр.

4. Балалар иҗаты нәтиҗәләренә ихтирам белән карыйлар.

5. Социаль әһәмиятле эшчәнлектә актив катнашалар, күргәзмәләр оештыруда катнашалар.

6. Балаларда рус һәм туган телләрендә нәфис сүз кабул итү нигезендә гүзәллек хисе формалаша.

**Тәрбия эшенең календарь планы**

| Үткәрү вакыты | Тема | Җаваплы |
|---|---|---|
| **Октябрь** | 1.“Көзге бал” бәйрәме | Салимова Л.Р. |
| **Ноябрь** | 1. "Джалилевские чтения " Халыкара әдәби конкурсы<br>2. Әңгәмә "Минем Туган Илем-Россия"<br>3. Әниләр көненә "Әни һәм бала"шигырь укучылар конкурсы | Салимова Л.Р. |
| **Декабрь** | 1. Дәрес " Татар халкының тормышы һәм гореф-гадәтләре белән танышу " темасы<br>2. "Яңа ел 2022"иртәсе | Салимова Л.Р. |
| **Январь** | 1."Балаларны татар мәдәнияте чыганакларына карау буенча иң яхшы почмак" тәрбиячеләр конкурсы | Салимова Л.Р. |
| **Февраль** | 1. Шигырь кичәсе “Муса Джалиль-поэт и герой!”<br>2.Театр”Әбиемнең бишек җыры” | Салимова Л.Р. |
| **Март** | 1. “8 март ” бәйрәме<br>2. Спектакаль “Беренче театр” | Салимова Л.Р. |
| **Апрель** | 1. Балаларның рәсем күргәзмәсе «Сказки Тукая». | Салимова Л.Р. |
| **Май** | 1.Минем бабам " темасына рәсем конкурсы оештырырга<br>2. Ата-аналарга дәрес күрсәтү | Салимова Л.Р. |

**Педагог өчен әдәбият исемлеге**


1. Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы. Шаехова Р.К., Казан, 2012.
2. Батыр-Болгари Л. “ Җырлап узган җәй”, Казан, “Мәгариф”нәшрияты, 2009.
3. ДәүләтшинаЛ.Х.“Бармакларны уйнатабыз- сөйләм телен үстерэбез”, Казан,2009
4. Закирова К.В. “Мәктәпкәчә тәрбия”, Казан, 1998.
5. 1.К В Закирова “Уйный-уйный үсәбез” ” Мәгариф”нәшрияты 2005.
6. 2.К.В.Закирова,Р.А.Борһанова,Г.Ә.Галиева...”Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программаның милли-төбәк юнәлеше.
7. ” Мәгариф”нәшрияты 2009.
8. 3.З.М.Зарипова,Р.С.Исаева,Р.Г.Кидрячева һ.б.”Балалар бакчасында рус балаларына татар теле өйрәтү”Программа,методик киңәшләр,диагностика.
9. 4. К. В. Закирова “балачак-уйнап- көлеп үсәр чак” Методик кулланма. Казан 2012
10. 5.Н.Р. Фәләхова “Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе” Методик кулланма Казан 2013
11. 6.З.М. Зарипова, Р.С. Исаева “Үстерешле уеннар” Методик кулланма Казан 2013


**Балалар өчен әдәбият исемлеге**


1. Зарипова З.М., Кидрәчева Р.Г., Шәрипова Л.Ә,...“Татарча сөйләшәбез” Методик кулланма, 6-7 яшь, Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2012.
2. Зиннурова Ф.М. “Үз илемдә, үз телемдә”, 2009.
3. Ибрагимова З.Г. “Күрсәт эле үскәнем”, Казан, “Мәгариф”нәшрияты, 2010.
4.“Татарча сөйләшәбез” 4-7 яшь, аудио-кушымта.
5. “Татарча сөйләшәбез” 4-7 яшь, видео-кушымта.

**Приложение 1**

**Мәктәпкә әзерлек төркеменең (6-7 яшь)**
**“Нәни артистлар” өстәмә эшенең**
**календарь планы**

| Үткәрү вакыты | Атна | Тема | Программаның эчтәлеге |
|---|---|---|---|
| **Октябрь** | 1 | **Танышу: “Курчаклар дөньясы”** | Төрле төр курчак театрлары (бармак, өстәл,бибабо ) белән таныштыру, алар белән эшләү үзенчәлекәрен карап китү. |
| | 2 | **“Өстәлдәге әкиятләр”** | Өстәл театрының үзенчәлекәре белән таныштыру; балалар белән курчаклар белән эшләүнең мөмкинлекләре турында әңгәмә. |
| | 3 | **“Өстәлдәге әкиятләр”** | Өстәл театры турында белемнәрне ныгыту; театр ширмасы турында сөйләшү; аның ни өчен кирәк булуын аңлатып китү. |
| | 4 | **Өстәл театры уйныйбыз** | Курчаклар белән эшләүне ныгыту;ширма белән эшләүнең берничә ысулы белән таныштыру. |
| **Ноябрь** | 2 | **Әкиятләргә сәяхәт** | Балалар белән белгән әкиятләрне искә төшерү; геройларына характеристика бирү. |
| | 3 | **”Теремкәй әкияте белән танышу”** | Әкият геройлары белән танышу.Курчаклары белән уйнау. |
| | 4 | **“Теремкәй” әкияте** | Әкиятне курчаклар белән уйнап карау. |
| **Декабрь** | 1 | “**Курчаклар да сөйләшә белә”** | Сәнгатьле сөйләм күнекмәләре үстерү; дикциягә,эмоциональ тавыш куелуга игътибар бирү. “Чуар тавык” әкиятен күрсәтү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 2 | **“Курчаклар да сөйләшә белә”** | Актерларның тавыш мөмкинлекләре турында әңгәмә,тавышның сәнгатьлелеген үстергә күнегүләр. |
| | 3 | **Әкият персонажлары** | Персонажлар турында әңгәмә; уен образлар тудыру өчен күнегүләр. |
| | 4 | **Әкият персонажлары** | Рольләрне әкият эчендә ныгыту,уйнау. |
| **Январь** | 1 | **Җырлы-биюле, такмаклы уеннар өйрәнү** | Сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерүне дәвам итү;. пантомимик күнегүләр. |
| | 2 | **Татар халык биюе (кызлар)** | Бию хәрәкәтләрен өйрәнү. |
| | 3 | **Татар халык биюе (малайлар)** | Бию хәрәкәтләрен өйрәнү. |
| **Февраль** | 1 | **М.Җәлилнең шигырьләренә иллюстрация** | Ясаган рәсемнәрне күзаллау. |
| | 2 | **М.Җәлилнең шигырь кичәсе** | Интонация, эмоциональ халәт өстендә эш. |
| | 3 | **Театр өчен атрибутлар әзерләү** | Интонация, эмоциональ халәт өстендә эш. |
| | 4 | **“Әбиемнең бишек җыры” исемле театрын сәхнәләштерү** | Балаларны бер-берсе белән килешеп эш итәргә өйрәтү; театрны сәхнәләштергәндә индивидуальлек тәрбияләү. |
| **Март** | 1 | **Без әкият язабыз** | Балаларның иҗади эшчәнлеген үстерү, әкият геройларының үзенчәлекләрен күрсәтә белү. |
| | 2 | **Төрле эмоцияләрне тасвирлау.** | Балаларны төле төр эмоцияәр белән таныштыру (шатлык,курку,гаҗәпләнү) |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | 3 | **Эмоцияне тавыш һәм мимика буенча таны!** | Балаларны төле төр эмоцияәр белән таныштыру (шатлык,курку,гаҗәпләнү) |
| | 4 | **Спектакаль “Беренче театр”** | Тавыш, жест, хәрәкәтләр ярдәмендә шул эмоцияләрне тасвирлау |
| **Апрель** | 1 | **Балаларның рәсем күргәзмәсе “Тукай әкиятләре”** | Үзләренең ясаган рәсемнәре турында сөйләү. |
| | 2 | **Г.Тукай “Кәҗә белән сарык”** | Әкият белән танышу, эчтәлеген аңлату. |
| | 3 | **Әкият геройлары белән танышу.** | Геройларга характеристика бирү, уйнап карау. |
| | 4 | **“Без-артистлар”** | Балаларның сүзәрне дөрес әйтүләренә, интонацияләренә игътибар итү; хәрәкәтләр өстендә эш. |
| | 5 | **Әкиятне сәхнәләштерү** | Әкиятне сәхнәләштергәндә мимика, ишарәләр, тавыш өстендә эш, аларны камилләштрү. |
| **Май** | 1 | **“ Без театр уйныйбыз! “** | Өйрәнгән әкиятләрне башка төркем балалары өчен сәхнәләштерү. |
| | 2 | **“ Без театр уйныйбыз! “** | Өйрәнгән әкиятләрне башка төркем балалары өчен сәхнәләштерү. |
| | 3 | **“ Без театр уйныйбыз! “** | Өйрәнгән әкиятләрне башка төркем балалары өчен сәхнәләштерү. |
| | 4 | **Соңгы дәрес** | Өйрәнгән әкиятләрне ата-аналар өчен сәхнәләштерү. |